ЯКШӘМБЕ
28 МАРТ
1943 ел.
№ 69 (6791)
Аерым номеры 20 тиен.

ВАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ПАРТИЯ САФЛАРЫН ҮСТЕРҮ БЕЛӘН ҖИТДИ РӘВЕШТӘ ШОГЫЛЛӘНЕРГӘ

Немец оккупантларына каршы бөек ватан сугышы көннәрендә Ленин-Сталин партиясенең хезмәт ияләре арасында авторитеты тагын да үсте. Совет халкы бөек большевиклар партиясе тирәсенә тагын да ныграк тупланды. Сөекле ватаныбызның азатлыгы, бәйсезлеге өчен алып барылган изге сугыш көннәрендә илебезнең алдынгылары, ВКП(б) сафларына кереп, үз ләренең тормышларын партиягә бәйләп, партиябез эше өчен бөтен көчләрен, кирәк булса тормышларын бирергә хәзер торганлыкларын күп тапкырлар исбат иттеләр. Б... Партиянең Татарстан оешмасы буенча гына да ватан сугышы көннәрендә ВКП(б) га член итеп 4.367, кандидат итеп 5.118 кеше кабул ителде.

Алексеевский районы, «Всход» колхозының кырчылык фермасында эшләүче иптәш Тюлянина күптән түгел генә ВКП(б) сафларына кабул ителде. Ул, коммунист дигән югары исемне аклау өчен, тагын да тырышып эшли башлады. Иптәш Тюлянина җитәкчелек итә торган ферма районда алдынгылардан берсе булып санала. Биектау районының Молотов исемендәге колхозның алдынгыларыннан иптәш Баһаветдинова ВКП(б) сафларына кергәннән соң хезмәт җитештерүчәнлеген ике—өч тапкырга күтәрде. Баш инженеры иптәш Кадышев булган Н-че заводның механигы иптәш Орлов, ВКП(б) членлыгына кандидат итеп кабул ителгәч, планны 300—400 процент итеп үти башлады. Күптән түгел генә ул «Социалистик ярыш отличнигы» значогы белән бүләкләнде. Мондый фактларны бик күп күрсәтергә мөмкин.

Ләкин партия-масса эшләре йомшак куелган, партия сафларына алуга тиешле игътибар бирмәгән урыннарда партия сафларының үсеше, бигрәк тә аның производство эшчеләре һәм колхозчылар исәбенә үсеше, һич тә канәгатьләнерлек түгел. ВКП(б) ның Куйбышев, Яңа Чишмә, Балык бистәсе, Лаеш, Кама тамагы һәм Чепья райкомнары һәм бу районнардагы башлангыч партоешмаларның күбесе партия сафларын үстерү буенча гафу ителмәслек начар эшлиләр. Бу районнарның партоешмалары ВКП(б) Өлкә Комитетының IX пленумы күрсәтмәләреннән нәтиҗә ясарга тиешләр.

Яшь коммунистларның, партия членлыгына кандидатларның идея-политик яктан үсүләре турында көндәлек кайгыртучанлык күрсәтү, аларны бөек партиянең лаеклы членнары итеп тәрбияләү—партоешмаларның иң мөһим бурычларыннан берсе. Ләкин партиянең кайбер оешмалары бу мәсьәләләргә җитди әһәмият бирмиләр. Мәсәлән, беренче тегү фабрикасы янындагы партоешма (секретаре иптәш Әхметшина) кандидатларның политик белемнәрен күтәрү, аларга партия порученияләре бирү белән җитәрлек шөгыльләнми. Шуның аркасында бу оешмада 1939 нчы елдан бирле ВКП(б) членлыгына кандидат булып торучыларның саны байтак кына. Мондый мисалларны башка күп кенә оешмалардан да китерергә мөмкин. Коммунистларны тәрбияләү кебек мөһим эшкә мондый җавапсыз караш кичекмәстән бетерелергә тиеш.

ВКП(б) Өлкә Комитетының IX пленумы партиянең барлык оешмаларыннан партия-оештыру һәм политик-масса эшен бүгенге көн бурычлары дәрәҗәсенә күтәрүне, партия сафларын туктаусыз ныгытуны, чыныктыруны, Ленин—Сталин эшенә чын күңелдән бирелгән алдынгы кешеләр исәбенә партия сафларын үстерү белән җитди рәвештә шөгыльләнүне таләп итте. ВКП(б) райкомнары һәм башлангыч партоешмалар пленум карарларын төгәл үтәргә тиешләр.

Совет Информбюросыннан

27 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

27 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

*Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр үзләре алган чикләрне ныгыттылар һәм разведка алып бардылар. Бер участокта немецларның бер батальон пехотасы, 3 танк ярдәме белән, безнең позицияләргә атака ясарга маташып карады. Н-че часть сугышчыларының уты белән дошман чигендерелде. Сугыш кырында дошманның 100 гә якын үле гәүдәләре һәм сафтан чыгарылган бер танкысы калды.

*Белгород районында Н-че часть подразделениеләре немецларга атака ясадылар һәм аларның окопларына бәреп керделәр. Штык сугышында безнең сугышчылар бер ротага якын гитлерчыларны кырдылар һәм дошманның позициясен алдылар. 6 пулемет, танкка каршы ата торган 2 орудие, күп кенә винтовкалар, бик күп патрон запаслары һәм бер радиостанция кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

*Чугуевтан төньяктарак безнең гаскәрләр оборона сугышлары алып бардылар. Немецларның күп тапкырлар ясаган атакаларын совет подразделениеләре кире кайтарды. Безнең артиллериябез уты белән немецларның 6 танкысы юк ителде. Шуның өстенә дошманның 2 танкысы мина кырында шартлады.

*Ильмень күленнән көньяктарак Н-че часть сугышчылары дошманның бер терәк пунктын алу өчен сугышлар алып бардылар. Бу уңайлы позицияләр 2 тапкыр кулдан-кулга күчте. Сугыш нәтиҗәсендә безнең подразделениеләр 120 гитлерчыны юк иттеләр, терәк пунктны дошманнан бөтенләй чистарттылар һәм анда ныгып урнаштылар. Төрле трофейлар кулга төшерелде.

*Кубаньда безнең подразделениеләр һөҗүм операцияләре алып бардылар һәм халык яши торган 2 пунктны алдылар. Бу пунктларның урамнарында дошманның 200 гә якын үле гәүдәләре табылды. Төрле сугыш милекләре төялгән 17 автомашина һәм повозкалар кулга төшерелде.

*Житомир өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды берничә көн эчендә 80 немец-фашист оккупантны юк иткән. Халык яши торган бер пункт янында партизаннар 300 ләп яшь үсмерләрне алып баручы жандармнарга һөҗүм иткәннәр. Совет патриотлары 36 гитлерчыны кырып ташлаганнар һәм немецлар тарафыннан Германиягә каторгага алып китәргә билгеләнгән совет яшьләрен азат иткәннәр.

*Түбәндә немецларның 299 нчы пехота дивизиясе фельдфебеле Шубертның көнлек дәфтәреннән аерым урыннар китерелә:

«...Двинскида тукталып торабыз. Бездән 50 километр алдарак бер поезд минага килеп бәрелгән һәм анда юлны төзәтәләр...

Монда бөтен җир партизаннар белән кайнап тора. Һәркайда да шартлау һәм поезд һәлакәте эзләре күренә. 100 километрлык араны 4 көн барырга туры килә. Монда партизаннар группалап хәрәкәт итәләр. Һәрбер куркынычсызлык хезмәте посты чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган. Бүген, без тукталып торган арада станциядән 2 поезд чыкты. Партизаннар беренче эшелонны үткәреп җибәрделәр, ә сугыш припаслары төялгән поездны шартлаттылар. Кешеләр житешмәгәнлектән партизаннарга каршы бернәрсә дә эшләп булмый. Аларның хәрәкәтеннән тимер юл транспорты зур зарар күрә...

Ахырында без киттек. Көндез сәгать 1 дә шуннан элек партизаннар тарафыннан тагын бер сугыш припаслары төялгән поезд шартлатылган урыннан үтәбез. Бу урын бөтенләй җимерек вагоннар белән капланган».

27 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

27 нче мартта фронтларда әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

*26 нчы мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән кимендә 50 автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар, 7 кыр һәм зенит артиллериясе батареясенең утын бастырдылар.

*Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр аерым участокларда үзләренең позицияләрен яхшырту өчен сугыш алып бардылар. Н-че часть сугышчылары, дошманның мина кырларын һәм тимер чыбык киртәләрен үтеп, халык яши торган 2 пунктны алдылар. Бу пунктлар өчен булган сугышларда немецларның 200 дән артык солдат һәм офицерлары үтерелде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

*Белгород районында бер участокта дошман зур югалтулар исәбенә безнең гаскәрләр урнашкан урынга үтеп керә алган иде. Омтылышлы контрудар белән немецлар элекке позицияләренә чигенделделәр. Сугыш нәтиҗәсендә ике ротага якын немец пехотасы юк ителде, дошманның 2 танкысы һәм бер самоход орудиесе сафтан чыгарылды.

*Төньяк Донецның урта агымы районында дошманның бер батальон пехотасы, көчле артиллерия уты ярдәме белән, командиры иптәш Краснов булган подразделениегә ике тапкыр һөҗүм ясады. Безнең сугышчылар гитлерчыларның атакаларын кире кайтардылар. Сугыш кырында дошманның 100 дән артык үле гәүдәләре калды. Икенче бер участокта Н-че часть разведчиклары дошманның траншейларына бәреп керделәр һәм 40 немец солдатын һәм офицерын юк иттеләр.

*Ильмень күленнән көньяктарак безнең частьлар үзләре алган чикләрне ныгыттылар һәм разведка алып бардылар. Сержант Платонов командалыгындагы 13 сугышчы, дошман позицияләренә шушып барып, гитлерчыларга кинәт атака ясадылар. Сержант Платонов бер немец офицерын үтергәннән соң 12 немец солдаты плен бирелде. Безнең разведчиклар яңа чиккә урнаштылар һәм ярдәмче көчләр килгәнчегә кадәр аны саклап тордылар.

Снайпер иптәш Номоконов сугыш башланганнан бирле 263 гитлерчыны, ә аның өйрәнчеге иптәш Миронов 126 гитлерчыны юк иттеләр.

*Кубаньда булган һава сугышларында безнең очучылар өч көн эчендә немецларның 34 самолетын бәреп төшерделәр һәм 8 самолетны зарарладылар. Совет штурмовиклары һәм бомбардировщиклары дошман аэродромнарына уңышлы һөҗүм ясадылар. Бомба ударлары һәм пушка-пулемет уты белән немецларның күп кенә самолетлары юк ителде.

* Гитлерчыларның бер җәза экспедициясе Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче, «За родину» исемле партизаннар отрядын чолгап алырга һәм юк итәргә маташкан. Немецлар, партизаннарның игътибарын алу максаты белән, аларга каршы сугышка бер подразделение җибәргәннәр. Карательләрнең төп көчләре, тылга төшеп, партизаннарның отрядын чолгап алырга һәм юк итәргә маташкан. Партизаннар разведкасы дошманның бу планын вакытында белеп алган. Отряд командиры, бер группа партизаннарны аерып алып, аларга немецлар подразделениесенә каршы сугышырга приказ биргән. Отрядның командир җитәктәкчелегендәге башка сугышчылары җәза экспедициясе үтәргә тиеш булган урман юлы янында засада ясаганнар. Гитлерчылар, партизаннарны чолгап алырга маташкан чакта, үзләре чолганышка килеп эләккәннәр. Совет патриотлары 94 немец солдатын һәм офицерын үтергәннәр, 2 кешене плен алганнар. Трофейлар кулга төшерелгән. Шулар арасында бер автомат орудие, 9 пулемет, 6 миномет, 50 винтовка, 2 автомат, 450 мина, азык төялгән 54 повозка бар.

* Түбәндә Смоленск өлкәсенең Гаврилки авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турынагы акт игълан ителә: «Немецлар чигенер алдыннан Кузнецово, Никулинки һәм башка авылларның халыкларын Гаврилкига җыеп китерделәр һәм берничә йортка куып керттеләр. Шуннан соң немец бандитлар авылга ут төрттеләр. Кайбер кешеләр котылмакчы булып карадылар. Алар ялкын белән чолганып алынган йортлардан урамга сикереп чыктылар. Якында гына торган немецлар качарга маташкан кешеләрне втоматтан атып үтерделәр. 100 дән артык кеше, шул исәптән күп кенә хатын-кызлар һәм балалар, утта янып үлде. Кызыл Армия частьлары кайбер совет гражданнарын бу коточкыч һәлакәттән коткарып кала алдылар». Актка авыл кешеләреннән А. Бритвин, Т. Медышкова, О. Свистова, Г. Котов, М. Семенова, Б. Котова, А. Лобанова һәм М. Жаворонковалар кул куйган.

СТАЛИН ЛАУРЕАТЛАРЫНЫҢ ВЗНОСЛАРЫ

Иптәш Сталин исеменә Сталин премиясе лауреатларыннан хатлар килү дәвам итә. Алар үзләренең иҗади эшләренә югары бәя биргән өчен халыклар юлбашчысына һәм Кызыл Армиянең полководецы иптәш Сталинга рәхмәт әйтәләр.

Сталин премиясе лауреатларыннан Г. Александров, Ем. Ярославский, И. Минц, П. Поспелов, М. Митин, Б. Быховский, Э. Генкин, В. Асмус, И. Разгон, Е. Городецкий, П. Юдин, О. Трахтенберг, М. Дынник, М. Григорьян һәм Л. Товстуха (хатыны) иптәш Сталинга хатларында болай дип язалар:

— Советлар Союзы халыкларының көч чыганаклары бетмәслек. һәм ул чишмәдәй ага. Безнең халкыбызны кол итәргә һәм аның культурасын юк итәргә омтылучы фашистик кабахәтләргә каршы ике ел барган авыр сугышта бу көчләрнең үсешен туктата алмады.

Алар 400.000 сум күләмендәге премияне «Алдынгы фән өчен» исемле танклар колоннасы төзүгә тапшыруны иптәш Сталиннан үтенәләр.

Үзбәкстан ССР ның халык артисты орденлы Мохтар Ашрафи «Сталин премиясе лауреатлары» исемле танклар колоннасы һәм авиаэскадрилья төзелешенә 50.000 сум кертә.

СССР ның халык артисты Александр Пирогов үзенең 100.000 сум күләмендәге премиясен Баш Командование фондына кертә.

Язучы Леонид Соболев үзенең 50.000 сум күләмендәге премиясен сакчылык катеры төзү фондына кертә һәм аңа үзенең Сталин премиясе алган «Морская душа» исемле хикәяләр җыентыгы исемен бирүне үтенә.

Иптәш Сталин үзенең җавабында лауреатларга сәламен җибәрә һәм Советлар Союзының кораллы көчләре турында кайгыртучанлык күрсәткән өчен аларга Кызыл Армиянең рәхмәтен белдерә.

(ТАСС).

Кызылармеец семьяларына ярдәм

Биектау районында соңгы көннәрдә кызылармеец семьяларына ярдәм итү эшенә аеруча зур әһәмият бирелә. Январь, февраль айларында гына да 319.423 сум пособие һәм пенсия түләнде. 65 семьяга 10.960 сум күләмендә бер вакытлы пособие бирелде, 74 семьяга 1.776 килограмм ашлык һәм 3.500 килограмм бәрәңге белән ярдәм күрсәтелде. Күп кенә кызылармеец семьяларына ярдәм тәртибендә аяк һәм өс киемнәре бирелде.

Кызылармеец хатыны иптәш Кондратьевага «Красное ядро» колхозы сыер бирде, иптәш Пеловага Калинин исемендәге колхоз бозау бирде. Аннары кызылармеец семьяларының балаларын балалар бакчаларына һәм яслеләргә урнаштыру чаралары күрелә.



Фронтка автотранспорт. Рәсемдә: Н-че заводта төзелгән вездиходлар фронтка китү өчен әзер торалар.

(ТАСС фотохроникасы).

АЗАТЛЫК ҖЫРЧЫСЫ

(МАКСИМ ГОРЬКИНЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕЛӘН)



Кешелек тарихында иң якты йолдызларның берсе булып балкыган бу бөек исемне татар халкы беренче тапкыр шагыйрь Габдулла Тукай авызыннан ишетте һәм аның иҗаты белән беренче тапкыр драматург Галиасгар Камал аркылы танышты. Шуннан соң бик күп еллар үткәч, шагыйрь Һади Такташ үзенең «Киләчәккә хатларында» аның белән очрашып күрешү шатлыгын язды.

Болар берсе дә очраклы фактлар түгел. Шулай ук татар халкы вәкилләренең Горький әсәрләрендә иң яхшы сыйфатлар белән сурәтләнүе дә очраклы хәл түгел. Татар халкы үзенең ватан сугышы фронтындагы улларына һәм кызларына язган сәлам хатында:

— «Син бөек язучы Максим Горькийны тәрбияләгән Идел йортта туып үстең»,—дип тикмәгә генә әйтми.

Боларның барсында да безнең халыкның бөек рус халкына һәм аның даһи художнигына тирән ихтирамы, туганлык мәхәббәте чагыла.

Максим Горькийның әдәбиятта һәм, гомумән, илебезнең культура үсешендә тоткан урыны бөек язучы булу белән генә чикләнми. Аның исеме ирекле тормышка, халыкка, туган илгә иксез-чиксез мәхәббәт, намуслы хезмәт символы булып тора. Шуңар күрә дә без ватан сугышының хәзерге иң кызу һәм хәлиткеч моментында аның исемен, азатлыкка юл яктыртып баручы Данко йөрәге төсле, ялкынлы факел итеп сафларыбыз өстендә күтәрәбез.

Җимерү һәм үтерүдән башка максатны белмәгән фашизмга каршы, кешелек дөньясының һәм кешегә хас барлык сыйфатларның явыз дошманына каршы каты сугыш барган көннәрдә, без Максим Горький әсәрләреннән җиңүгә дәрт һәм дәрман табабыз.

Кеше һәм Хезмәт—бу ике сүзне Горький зур хәрефләр белән башлап язарга ярата һәм аларны үзенең иҗаты өчен дә төп тема итеп сайлаган иде.

«Минем университетларым» исемле әсәрендә ул:

«Хезмәтнең героик шигъриятен беренче тапкыр сизгән көнемне бик яхшы хәтерлим,—дип яза һәм Казан устьесендагы грузчикларның эш көнен сокланып туймаслык сүзләр белән сурәтли:

— «Алар эшкә сусаган төсле, дүртәр потлык капчыкларны кулдан-кулга ыргыту һәм җилкәгә тюклар күтәргән килеш йөгереп үтү ләззәтен сагынып көткән төсле, эшлиләр.

...Мин дә, капчыкларны алар шикелле тотып, күтәреп алам, ыргытам һәм тагын йөгереп киләм, тагын күтәреп алам, миңа бөтен әйләнә-тирә һәм мин үзем шушы давыллы биюдә бөтерелеп әйләнәбездер һәм айлар-еллар буенча үзләрен аямыйча, ару-талуны белмичә шушындый күңелле итеп эшләүче бу кешеләр, шәһәрдәге чиркәү һәм мәчет манараларын да куптарып алып, теләсә кайда күчереп куя алалардыр төсле күренде.

Бу төнне мин аңарчы кичерергә туры килмәгән шатлык эчендә үткәрдем, минем йөрәгемә бөтен гомер буена шушылай онытылып эшләү теләге туды... Менә бу шатлыклы, ярсулы көчкә бернәрсә дә каршы тора алмый һәм ул борынгы әкиятләрдә сөйләнгән төсле, бер төн эчендә бөтен җир йөзен матур сарайлар, шәһәрләр белән бизи ала, җир йөзендә могъҗизалар тудыра ала кебек тоелды».

Горькийның барлык иҗатында шушы дәртле, күңелле, героик хезмәт җыры янгырый һәм бу җыр безне, ирекле хезмәт белән яшәүче совет кешеләрен, кол итәргә омтылучы Гитлер бандасына каршы рәхимсез көрәшкә чакыра.

Горькийның бөтен иҗаты—хезмәт сөюче ирекле кешегә дан гимны.

— «Кеше! Минем йөрәгемдә ул кояш кебек булып туа һәм шуның яктысында дөнья кебек колач җитмәс мәһабәтлек белән алга һәм югарыга атлый ул—гүзәл Кеше.

Ул үзенең хезмәтен, горур юлын йөрәк каны белән чылатып атлый. Мәһабәт, горур һәм ирекле караш белән ул чынлык күзләренә карый,

Кешедә барысы да бар, барысы да Кеше өчен!...

Шулай атлап бара ул тынычсыз Кеше—алга! Һәм югарыга! Һаман алга! Һәм югарыга!»

Без хәзер шушы бөек тойгы, ирекле кешегә, аның көченә, аның җиңүенә нык ышаныч белән рухланган хәлдә изге сугыш алып барабыз. Кешелек дөньясының иң явыз дошманына-фашизмга каршы үлем сугышы алып барабыз.

Бу сугышта Горький һәм аның мәңгелек иҗаты безнең белән бергә бара. Верховный Баш Командующий даһи полководец иптәш Сталин үзенең тарихи приказында аның ялкынлы сүзләрен сугышчан лозунг итеп ала:

— «Әгәр дошман бирелмәсә, аны юк итәләр».

Һәм без туган илебезнең газиз туфрагын канлы итекләре белән таптарга килгән немец юлбасарларын кырып бетергәнче сугышачакбыз.

Безнең орудиеләребезнең көчле залпларында, алга баручы Кызыл Армия батырларының корыч адымнарында бөтен дөнья үч авазын, дәрт ялкынын һәм җиңү давылын ишетә!

— Давыл! Көчлерәк күкрәсен давыл!

Азатлык җырчысы Горький шулай дип җырлады һәм ул дәртле җырны без бүген, яңа көч белән азатлык сөюче барлык халыкларның телләрендә күтәреп алабыз.

КАВИ НӘҖМИ.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ТЕОРЕТИК КОНФЕРЕНЦИЯ ХӘЗЕРЛЕКЛЕ ҮТТЕ

Партоешма секретаре иптәш Гольман булган заводта соңгы көннәрне теоретик конференцияләр үткәрелә башлады. Партия безнең тарихын, илебезнең азатлыгы өчен барган сугыш чорында юлбашчыбызның күрсәтмәләрен өйрәнүдә бу конференцияләр зур ярдәм итәләр.

Заводның баш технологик бүлеге янындагы партоешма күптән түгел генә теоретик конференция үткәрде. Конференция иптәш Сталинның 1942 нче елның 6 нчы ноябрендә ясаган доклады буенча булды.

Конференциядә «Тылда оештыру эше» темасы буенча — Фабричев, «Совет-немец фронтында сугыш хәрәкәтләре» темасы буенча—Малаховский, «Европада икенче фронт турындагы мәсьәлә» темасы буенча—Зейгермахер, «Гитлер Германиясе нә һәм аның Европадагы союзникларына каршы СССР ның, Англиянең һәм АКШ ның сугышчан союзы» темасы буенча—Шейгфайн һәм «Безнең бурычлар» темасы буенча—Астафьев иптәшләр доклад ясадылар.

Конференциядә доклад ясаган иптәшләр юлбашчыбыз иптәш Сталинның ватан сугышы көннәрендә ясаган докладларыннан, «Ленинизм мәсьәләләре» нән; «ВКП(б) тарихының кыскача курсы» ннан һәм иптәш Ленинның хезмәтләреннән уңышлы файдаландылар.

Конференциядә барлыгы 12 кеше чыгыш ясады. Фабричева, Зейгермахер, Якушев иптәшләр конференциянең эшендә aеруча актив катнаштылар.

М. ШВАРЦЕР.

Йорт хозяйкалары арасында эшләүне тиешле югарылыкка күтәрик

Йорт хозяйкалары арасында большевистик агитация эшләре алып бару — иң әһәмиятле бурычларның берсе.

Ләкин партия оешмаларының кайберләре бу эшкә тиешенчә бәя бирмиләр. Мәсәлән, Шәһәр Советы янындагы партоешмага беркетелгән 11, 13, 15 нче йорт идарәләрендә 1943 нче елның башыннан бирле бер тапкыр да беседалар үткәрелмәгән. Биредә партоешма тарафыннан билгеләнгән агитаторлардан Макарова, Хисматуллин, Петров һәм Гонишенко иптәшләр, контроль юклыктан файдаланып, җавапсызлык күрсәтәләр.

Баш инженеры иптәш Кадышев булган завод янындагы партоешмага ике йорт идарәсе беркетелгән. Партоешма бу йортларда политик-агитация эшләре алып бару өчен бер агитатор билгеләү белән тынычланган. Ә Горпромторг янындагы партоешма йорт хозяйкалары арасында эшләү өчен хәтта агитатор да билгеләмәгән. ВКП(б) райкомы бюросында партоешма секретаре иптәш Хәбибуллинага бу эшкә җавапсыз караганы өчен кисәтү ясалган иде. Аннан соң инде ай ярым вакыт үтте. Ләкин эштә һаман да борылыш ясалмаган. Мондый фактларны Бауман районыннан байтак күрсәтергә мөмкин.

ВКП(б) райкомының агитация-пропаганда бүлеге дә (мөдире иптәш Вәлиуллина) агитаторларның эшләренә тиешле җитәкчелек итми. Агитаторлар өчен семинарлар бик сирәк үткәрелә. Алдынгы агитаторларның тәҗрибәләрен урталашу канәгатьләнерлек оештырылмаган.

Партия һәм комсомол оешмалары йорт хозяйкалары арасында эшләүне юлга салырга, һәрбер агитаторның эшенә конкрет ярдәм һәм контроль булдырырга тиешләр.

С. АХМЕТОВА.

МӘКТӘПЛӘРДӘ

ЧЫНЫККАН КАДРЛАР ТӘРБИЯЛИК

Без шәһәрнең Сталин районындагы урта мәктәпләрнең берсенә килеп керәбез. Дәрескә чакырып звонок шалтырый. Расписание буенча 7 нче класста хәрби эш буенча занятиеләр үткәрелергә тиеш.

Класска хәрби җитәкче килеп керә. Класстагы дежурный укучы—аякка басыгыз!—дип команда бирә. Ул нык адым белән хәрби җитәкче янына килә һәм күпме укучының килүе, кемнәрнең килми калуы турында рапорт бирә. Занятиеләр башлана. Бүгенге тема—винтовканың материаль частен белүне тикшерү

Укучыларга бирелгән сорауларга җавап алганнан соң, хәрби җитәкче укучыларның өлгерешләре языла торган журналга отлично, яхшы, канәгатьләнерлек билгеләре куя: начарлар юк.

Күрше класста икенче занятие «күзәтүче сугышчы», «элемтәче сугышчы» темаларына үткәрелә. Иң соңгы занятие «строй әзерлеге турында» бара.

Занятиеләрдә укучыларның хәрби эшне шактый үзләштерүләре, дисциплинага өйрәнгәнлекләре сизелә. Шул рәвештә мәктәпләрдә яшьләрне физик нык, чыдамлы һәм дисциплиналы кадрлар итеп тәрбияләү эше бара.

***

Шушы көннәрдә Сталин районы мәктәпләрендә укучылар хәрби-тактик уеннарда катнаштылар. Укучылар подразделениеләргә берләшкән хәлдә, билгеләнгән урынга байраклар күтәреп һәм барабаннар кагып бардылар. Алар арасында укучылар, пулеметчиклар, автоматчиклар, минометчиклар һәм разведчиклар бар иде. Алар һәммәсе дә үзләренә билгеләнгән кораллар-ның макетларын алып килгәннәр. Укучыларның кайберлере маска халатлар кигәннәр.

Подразделениеләр,сугышчан приказ алганнан соң, яшерен юллар аркылы Кабан күле буенда, Лозовский урамы башындагы районда оборона өчен билгеләнгән урынга бардылар. Аларга каршы Бауман һәм Молотов районнарындагы укучылар һөҗүмә килергә тиешләр иде. Бер сәгатьтән соң дозорлар һәм разведчиклар каршы якның алгы частьлары килә башлаганлыкны хәбәр иттеләр. Озак та үтмәде, кар өстендә аерым кешеләр күренә башлады. Алар Сталин районы укучылары урнашкан позицияләргә якынлаша башладылар. Минометчиклар аларга ут ачтылар, миналарның ничек очып баруларын күрсәттеләр. «Сугыш» башланып китте. Каршы яктагылар якын килә башлагач, оборонада торучыларның уң флангысы контратакага күчте һәм «ура!» тавышлары яңгырады. Каршы якның атакасы кире кайтарылды, һәм ул элекке позицияләренә чигенде.

Уен тәмам булганнан соң тикшерү үткәрелде. Уенда катнашучылар командованиенең карарын зур кызыксыну белән тыңладылар. Сталин районының беренче ротасы сугышны алып барауда беренче урынны алды. Укучыларның башка подразделениеләре дә шактый зур осталык күрсәттеләр.

Хәрби уенның ничек үткәрелүен тикшерү тәмам булды. Команда бирелде. Подразделениеләр колонналарга тезелгән хәлдә, җырлый-җырлый мәктәпләргә таралдылар.

И. КОНЕВСКИХ.

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

ЯҢА НОРМАЛАРНЫ УҢЫШЛЫ ҮЗЛӘШТЕРДЕЛӘР

Партком секретаре урынбасары иптәш Закиров булган N-че заводның цехларында һәм бригадаларында Май алды социалистик ярышы җәелгәннән җәелә бара. Мәсәлән, кою-шлифовка цехы ярышка чыкканнан соң үзенең эшен аеруча яхшыртты. Бу цехның күп кенә стахановчылары эшләп чыгару буенча яңа нормаларны уңышлы рәвештә үзләштерәләр. Стахановчы шлифовщица иптәш Юданова, яңа нормаларны үзләштереп, көнлек заданиене 150 дән алып 260 процентка кадәр үти башлады. Формовщик иптәш Мишин брак процентын шактый киметте, көненә бер ярым норма бирүгә иреште.

Фронтовик хатыны шлифовщица Галия иптәш Вәлишова моңа кадәр 3 станокта эшли иде. 10 нчы марттан алып, ул 4 станокка хезмәт күрсәтүгә күчте. Хәзер иптәш Вәлишова, 5 станокта эшләп, яңа нормаларны 130-140 процентка үти.

Цехтагы эшчеләр эшләп чыгару буенча яңа нормаларны арттырып үтәп, Май алды ярышында җиңеп чыгу өчен көрәшәләр.

Партбюро секретаре иптәш Гайнуллин булган цех коллективы үз алдына Май алды ярышында планнан тыш күп кенә өстәмә продукция эшләп чыгару бурычын куйды. Бу бурычны үтәү өчен һәркем планын арттырып үтәргә тырыша. Бушатучы иптәш Кочиев авыр эштә смена заданиесен һәр көн саен 130—140 процентка үтәп бара. Аппаратчицалардан Камалетдинова, Нуруллина, Галиева, Данилова, Сабирова иптәшләр планнарын 120 дән алып 170 процентка кадәр үтиләр.

Цехком председателе иптәш Бабушкин булган цехтагы кайбер бригадалар, эштә кыенлыклар булуга да карамастан, хезмәт җитештерүчәнлегенең гүзәл үрнәкләрен күрсәтәләр. Мәсәлән, иптәш Егорова җитәкчелегендәге стахановчылар бригадасы март аенда ярышта алда бара. Бу бригада, яңа нормалар белән эшләп, нормаларны 150—170 процентка кадәр үтәүгә иреште.

Иң авыр операцияләрдә эшләүче Молочкова, Михайлова, Кожевников иптәшләрнең бригадалары да яңа нормаларны һәркөн 115 тән алып 150 процентка кадәр үтиләр. Эштә патриотизм үрнәкләрен күрсәткән цехларны, сменаларны, бригадаларны һәм аерым стахановчыларны бик күпләп санарга мөмкин.

Безнең завод коллективы Кызыл Армия Баш Командованиесенең куәтле фондын төзүгә әнә шулай катнаша.

М. ГУМЕРОВ.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

Югары уңыш өчен походка!

Трактор—бу походта җиңүгә ирешүдә көчле средство. Барлык машиналарны тизрәк төзәтик һәм аларның сезон буенча нормаль эшләүләрен тәэмин итик!

Колхозларның ОРЛЫК ФОНДЫНА

Совет патриотлары взносы

82. **Галиев К.**—Буа районы, Фрунзе исемендәге колхоз члены—10 пот ашлык һәм 10 пот бәрәнге бирде.

83. **Латипов** — Буа районы, Фрунзе исемендәге колхоз члены—10 пот ашлык һәм 10 пот бәрәнге бирде.

84. **Фомин Д.** — Буа районы, Молотов исемендәге колхоз члены—12 пот ашлык һәм 6 пот бәрәнге бирде.

85. **Аглятова Е.**—Буа районы, Молотов исемендәге колхоз члены—12 пот ашлык һәм 6 пот бәрәнге бирде.

86. **Мөяссәрова М.**—Кызыл йолдыз районы, Калинин исемендәге колхоз члены—15 пот ашлык, 21 пот бәрәнге, шуның өстенә Кызыл армиягә бүләккә 7 пот борчак бирде.

87. **Абдрашова Л.**—Кызыл йолдыз районы, «Авангард» колхозы члены—18 пот арыш, 12 пот борчак, 18 пот бәрәнге һәм Кызыл Армиягә бүләккә 3 пот борчак кертте.

88. **Кушаев И.**—Кызыл йолдыз районы, «Авангард» колхозы члены—21 пот ашлык, 6 пот бәрәнге һәм Кызыл Армиягә бүләккә 4 пот ашлык бирде.

89. **Муткин А.**—Кызыл йолдыз районы, «Восход» колхозы члены—30 пот ашлык, 18 пот бәрәнге бирде.

90. **Муткин П.**—Кызыл йолдыз районы, «Восход» колхозы члены—24 пот ашлык һәм 24 пот бәрәнге бирде.

Фәйзуллина, Гымадеев, Шиһапов иптәшләрдән үрнәк алыгыз

Тархан районының «Берлек» колхозы члены, фронтовик хатыны иптәш Фәйзуллина, колхозның чәчүлек орлык фондына 120 пот ашлык биреп, ил патриоты булуын күрсәтте.

Шул ук колхоз члены, ватан сугышында катнашкан Гафар иптәш Гыймадиев та колхозга 48 пот бөртекле ашлык бирде.

Бу колхозда тик бер көн эчендә генә дә 50 центнер орлык җыелды.

Мөслим районының «Кызыл көч» колхозы члены иптәш Х. Шиһапов, колхозга 72 пот орлык биреп, бик яхшы үрнәк күрсәтте.

ОРЛЫК ТУПЛАНА

САРМАН, 27 март. (Телефон буенча). Районда чәчү орлыклары әзерләү уңышлы бара. «Хезмәт» колхозы членнары үзләренең гомуми җыелышларында колхозны чәчү орлыгы белән тәэмин итәргә сүз биргәннәр иде. Беренче башлап иптәш Кадыйров чәчүлек өчен 25 пот бодай һәм 2 пот бәрәнге бирде. Зәйнәп иптәш Җамалова 18,6 пот ашлык, 18,5 пот бәрәнге, В. Рәхимов һәм Хәкимов иптәшләр икешәр центнер ашлык һәм икешәр центнер бәрәнге бирделәр.

Сталин исемендәге колхоз членнары үз колхозлары өчен 450 пот бодай, борчак, солы, 135 пот бәрәнге җыйдылар.

Орлык белән колхозара ярдәм дә җәелә. Хәзер районда барлыгы 5.000 потка якын ашлык, 5.000 пот бәрәнге, 1.000 поттан артык бәрәнге кисентеләре җыелды.



Ключи МТС ы тракторчысы иптәш Г. Никонов, үз бригадасындагы тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны 1943 нче елның 23 нче февраленә тәмамларга йөкләмә алган иде. Бу йөкләмәсен ул срогыннан алда үтәде һәм шуның өстенә икенче бригаданың бер тракторына да ремонт ясады. Хәзер иптәш Никонов һәм аның бригадасы члennары башка бригадаларга ярдәм итәләр. Рәсемдә: (уңнан сулга) Г. Никонов һәм тракторчы М. Царева иптәшләр тракторга ремонт ясыйлар.

К. Тахтеев фотосы.

Гамсезлеккә чик куелсын

Арча районы колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары фронт һәм илебез алдындагы бурычларны үтәп, азык продуктларын торган саен күбрәк җитештерү өчен нык тырышып эшлиләр.

Быелгы язгы чәчүне агротехник срокларда үткәрү чәчүлек орлыкның җитәрлек һәм яхшы сыйфатлы булуына бәйләнгән. Район колхозлары шушы төп бурычны хәл итү уңи көнлегендә шактый яхшы эш күрсәттеләр. Колхозчылар шуңа мобилизацияләнделәр. Чәчүлек орлыгы җитми торган колхозлар өчен орлык туплауны оештыруда колхоз җитәкчеләренә ярдәмгә район активы җибәрелде.

«Спартак» колхозы членнары бу өлкәдә аеруча актив катнашалар. Алар уңи көнлекнең беренче көннәрендә үк район орлык фондына 1.300 пот бәрәнге һәм 425 пот бөртекле ашлык тапшырдылар. Колхоз председателе иптәш Сабиров 21 пот ашлык, 18 пот бәрәнге биреп торды. Колхозчылардан Гайнетдинов 18 пот ашлык һәм 18 пот бәрәнге бирде. Латыйпов, Солтанов иптәшләр 12 шәр пот ашлык китерделәр.

Шушындый зур политик әһәмияте булган эшкә—орлык әзерләүгә җавапсыз караучы җитәкчеләр дә бар әле. «Мәдәният» колхозын алыйк. Анда уң көнлек башлангач та, чәчүлек орлык фондына 2,5 центнер ашлык һәм 5 центнер бәрәнге тупланган иде. Бу һаман да шуннан артмый, Анысы да колхоз председателе Гыйльметдиновның һәм 2 бригадирның взнослары гына. Биредә колхозчыларның үз колхозларына бурычка ашлык биреп торырлык мөмкинлекләре бар. Тик аңлату эше генә юлга салынмаган. Комсомол оешмасы секретаре иптәш Әхметова, агитколлектив җитәкчесе Гайнуллина иптәшләр бу эшне оештыруның инициаторлары булырга тиешләр иде. Ләкин алар бу чараны үткәрүне оештырмау гына түгел, хәтта мөмкинлекләре була торып та, үзләре аннан читтә калырга тырышалар.

Чәчүлек орлык иген уңышының төп чыганагы булып торганлыктан, орлык туплау эшенә җавапсыз һәм гамьсез караучылыкка чик куелырга тиеш.

Н. ХАЙРУЛЛИН.

Яшь тракторчылар практик эшкә әзерләнәләр

КАРГАЛЫ, 27 март. (Телефон буенча). Каргалы МТС ында быел күп кенә яшь тракторчылар артты. Аларның күбесе трактор йөртергә өйрәнү буенча теоретик һәм практик белемне отлично үзләштерделәр. Ремонт эшендә катнашып, машиналарның аерым частьларын җентекләп өйрәнделәр. Яшь тракторчы Бибиҗамал Юсупова «У—2» тракторында сменага 500 гектар җир сөрергә һәм 550 килограмм ягулыкка экономия ясарга, техуходны үз вакытында үткәреп, тракторны тулы нагрузка белән йөртергә йөкләмә алып, Рәхилә иптәш Фәттахованы ярышка чакырды. Кәримова, Шәрәфетдинова, Хәйруллина һәм Сабирова иптәшләр дә «СТЗ» тракторында, 1943 нче елгы сезонда 500 әр гектар җир сөрергә, күп кенә ягулыкка экономия ясарга һәм тулы нагрузка белән эшләргә тырышырга булдылар.

Моның өчен тракторларның төзелешен яхшы белергә, аны саклап йөртергә кирәк бит. Бу өлкәдә алар тәҗрибәле тракторчылар белән элемтә тоталар һәм алардан өйрәнәләр.

ЙӨКЛӘМӘНЕ ҮТИБЕЗ

Яз килде. Күп көч һәм оешканлык таләп итеп, сабан өсте җитә. Аның уңышлы үтүе МТС ларның колхозларга яхшы хезмәт күрсәтүенә бәйләнгән. Без моны яхшы аңлыйбыз һәм шуны истә тотып, тракторларны, тагылма инвентарьларны, комбайннарны ремонтлауның сыйфатына бик нык игътибар иттек.

Ремонт мастерскоенда көндез дә, төнлә дә эш туктап тормады. Ремонтта эшләүчеләр 15 әр сәгать буена станоклар яныннан китми эшләделәр. Коммунистлардан һәм комсомолецлардан Сабиров, Габдрахманов, Хәбиев, Хәтмуллин, Әгъламов, Сәрвәров, Пуршинкин һәм Нуретдинов иптәшләр көндәлек эш нормаларын 200—300 процент итеп үтәделәр. Алар ремонт өчен кирәкле запас частьларны үзләре таптылар. Искеләрне реставрацияләү, яраклаштыру чараларын күрделәр. Нәтиҗәдә, без барлык тракторларны да 10 нчы февральдә үк ремонтлап бетердек.

Рязань өлкәсе, Рыбново МТС ының Дарья Гармаш бригадасының хатын укыганнан соң, МТС коллективы Бөтенсоюз социалистик ярышына кушылып, яңа йөкләмәләр алды. Ул йөкләмәләр комбайннарны һәм тагылма инвентарьларны төзек хәлгә китерү буенча конкрет чаралардан тора. Хәзер комбайн моторларының һәм җедерларының 25 проценты, тагылма инвентарьларның 95 проценты төзәтелде инде. Болар өстенә күп кенә детальләр реставрацияләнде.

Тагылма инвентарьларга реставрация ясауны һәм комплектовать итүне 1 нче апрельгә тәмамларга булдык. Ашлык суту машиналарына ремонтны 1 нче июньдә төгәлләүне планлаштырдык.

Алган йөкләмәләрнең үтәлеше ай саен тикшерелә. Без үзебезнең хезмәттәш дусларыбыз—Красный бор МТС ының тракторчыларын һәм комбайнчыларын ярышка чакырдык.

Актаныш МТСы тракторчылары: Шәмсиев, Кадимова, Габдрахманов, Мөҗәев, Әлмөхәметов, Борһанова.

ТУЛЫ ӘЗЕРЛЕК БЕЛӘН

АКТАНЫШ, 26 март. (Телеграф буенча). «Актанышбаш» колхозы быелгы язгы кыр эшләрен тулы әзерлек белән каршылый. Биредә авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясалган, дилбегә, камыт һәм башка шундый кирәк-яраклар барысы да җитәрлек булдырылган. Колхоз үзенең чәчү мәйданына җитәрлек итеп орлык әзерләп куйган. Алар коры урыннарда саклана. Орлыкларның тишелеп чыгышы тикшерелгән.

Миңзәләлеләр үрнәгендә колхозчылар үз хуҗалыкларындагы запаслардан артык ашлыкларын колхозларга орлыкка бирәләр. Х. Шәйхетдинов—37 пот, Х. Камалиев—30 пот, М. Камалова һәм Хәбибрахманов иптәшләр 30 ар пот ашлык бирделәр. Моннан тыш колхозның орлык фондыннан күрше колхозларга 1.830 пот ашлык бурычка бирелде. Колхозчылар барлыгы 671 пот ашлык җыеп бирделәр.

З. ЗАКИРОВА.

Сталинградны ТӨЗЕКЛӘНДЕРИК

Электромоторлар һәм станоклар

Вахитов исемендәге жиркомбинат коллективы фашистик ерткычларга каршы героик көрәш алып барган Сталинград шәһәренә җибәрү өчен зур көчле 15 электромотор; бер ваакум насос, бер строгаль станогы һәм башка бик күп төрле әйберләр әзерләде. Комбинатта төрле запас частьлар, инструментлар әзерләү һәм башка әйберләр җыю эше дәвам итә.

***

Киез итек фабрикасының эшчеләре һәм инженер-техник работниклары Сталинград өлкәсенә бер вагон киез; 500 пар киез туфлялар һәм 50.000 сумлык төзү материаллары; шулай ук башка төрле йорт кирәк-яраклары җибәрәләр. Героик шәһәр өчен акчалата ярдәм туплау эше дә дәвам итә.

***

Героик Сталинградка ярдәм итү буенча бөтен халык тарафыннан башланып киткән патриотик хәрәкәткә партком секретаре ярдәмчесе иптәш Козлов булган завод коллективы зур дәрт белән кушылды. Халыклар юлбашчысы иптәш Сталинның бөек исемен йөртә торган бу шәһәрне тизлек белән аякка бастыру өчен эшчеләр бөтенесе дә эшләргә әзер торалар.

Начальнигы иптәш Александров булган цехның группа мастеры иптәш Кудрявцев эш вакытыннан тыш 6 кастрюля эшләргә, электромонтер иптәш Савин 6 моторга ремонт ясау йөкләмәсен алдылар. Мастер иптәш Качкин группасы 8 кастрюля әзерли. Цех коллективы 28 нче мартта ял көнне стахановчы вахтага басып, бу көнне эшләгән хезмәт хакын тулысынча Сталинградка ярдәм фондына тапшырырга карар бирде.

Комсорг иптәш Перевезенцев булган цехның комсомолецлары Сталинград ашханәләре өчен 150 куржка, 150 кашык, кастрюльләр һәм башка йорт кирәк-яраклары әзерлиләр.

КОМСОМОЛ —ЯШЬЛӘР ӨМӘЛӘРЕ

Казан шәһәрендәге промышленность предприятиеләре комсомол оешмаларының кара металл ватыкларын һәм калдыкларын җыю, ешкәртү, ташу буенча өмәләр үткәрү турындагы инициативасын яклап, ВЛКСМ Өлкә Комитеты бюросы карар бирә: 1943 нче елның 28 нче мартында шәһәр күләмендә, 4 нче апрельдә республика күләмендә кара металл җыю, ешкәрту һәм ташу буенча комсомол-яшьләр өмәләре үткәрергә. Өмәләрдән килгән акча Сталинградка ярдәм фондына кертеләчәк.

Өмәләрдә актив катнашу, героик Кызыл Армия өчен сугыш припаслары, винтовкалар, пулеметлар, минометлар, орудиеләр, танклар һәм самолетлар эшләп чыгаруны арттыруда металлургия заводларына ярдәм итү, Сталинградны аякка бастыруда ярдәм итү—һәрбер комсомол оешмасының намус эше.

АГЫМДАГЫ СЧЕТ № 160143

Сталинградка ярдәм итү һәм Сталинград шәһәрен төзекләндерү фондына керә торган средстволарны учетка алу өчен Дәүләт банкысының Татарстан конторасы 160.143 нче номерлы махсус агымдагы счет ачты.

Гитлерчы ялганчылар тынмыйлар

Совет Информбюросы немецларның Төньяк Донец белән Днепр арасындагы районда безнең гаскәрләрнең югалтулары турындагы ялганнарын фаш иткән иде инде. Ләкин гитлерчы ялганчылар һаман да тынмыйлар. Гитлерчыларга бер ялганны игълан итү аз булып күренгән һәм алар тиз генә шундый ук тупас һәм ахмак яңа ялган әвәләп чыгарганнар. 24 нче мартта Германия информация бюросы совет гаскәрләренең соңгы 8 атнада Орел районында булган югалтулары турында белдерү игълан итте. Бу юлы гитлерчылар 41 нче укчы дивизиянең, 11 укчы һәм 18 танк бригадаларының юк ителгәнлеген яки «аеруча авыр югалтуларга» дучар булганлыгын игълан иттеләр. Эш шунда ки, Орел районында безнең ул кадәр гаскәребез юк иде һәм хәзер дә юк. Әгәр дә бу районда безнең шул кадәр гаскәребез булса иде, немец гаскәрләренең эзе дә калмаган булыр иде.

Мәгълүм ки, гитлерчылар пропагандасы беркайчан да акыллы булмады һәм еш кына үзенең мәгънәсез ялганнары белән үзен ахмак хәлгә калдырды. Ләкин Сталинград янында немец-фашист гаскәрләре җиңелгәннән соң гитлерчылар пропагандасы тагын да ахмакланды һәм һәр төрле сәламәт акыл калдыкларын бөтенләй югалтты. Гитлерчыларның соңгы хәбәрләренең котырган саташулары моны барыннан да яхшырак раслый. Чыннан да, 1943 нче елның 20 нче мартында немецлар, үзләренең Төньяк Донец белән Днепр арасындагы районда булган уңышларын төрлечә күпертеп, дистәләрчә совет дивизияләренең һәм бригадаларын юк ителгән дип игълан иттеләр. 4 көн үткәч, 24 нче мартта, Кызыл Армиянең гүяки юк ителгән бу берләшмәләренең бер өлешен, мәсәлән, 193 нче укчы дивизияне, 9 нчы чаңгы бригадасын һәм башкаларны гитлерчылар, инде икенче тапкыр, юк ителде дип игълан итәләр, ләкин бу юлы инде алар Төньяк Донец белән Днепр арасындагы районда түгел, бәлки Орел районында юк ителгәннәр имеш.

Гитлерчы ялганчыларга ышанган тәкъдирдә болай килеп чыга: Кызыл Армия Фронтның ике участогына да—Төньяк Донец белән Днепр арасында 13 нче февральдән 20 нче мартка кадәр һәм Орел районында 8 атна эчендә 160 дивизия һәм бригада югалткан. Шушындый сорау туа: алай булгач, Курск һәм Орел районында, Вязьма һәм Ярцево районында, Брянск һәм Старая Русса районында немец-фашист гаскәрләрне кыруны һәм тар-мар итүне кем дәвам иттерә соң? Аннары. Немецларга үзләренең фронтларын кыскарту нәрсәгә кирәк булган? Немецларның фронтны кыскартырга мәҗбүр булулары аларның эше яхшы барганнан түгел бит. Немецларның информация бюросындагы ялганчыларның тиешеннән артык тырышлык күрсәткәнлекләре һәм үз хуҗаларын алдаганлыклары ачык күренеп тора. Чыннан да, җүләргә намаз укырга кушсаң, маңлаен тишәр дигән мәкаль монда бик туры килә.

Орел районында эшнең чын торышына килгәндә түбәндәгеләрне әйтергә кирәк: январь ахырында фронтның бу участогында хәрәкәт итүче безнең гаскәрләр күп кенә урыннарда немецларның оборона линияләрен өзделәр һәм шактый зур территорияне алдылар. Бу сугышлар барышында совет гаскәрләре кимендә 20.000 немец солдатын һәм офицерын, дошманның бик күп техникасын юк иттеләр; трофейлар кулга төшерделәр һәм 5.000 кешене плен алдылар. Шул ук вакыт эчендә безнең гаскәрләрдән 8.620 кеше үтерелде һәм яраланды.

Март уртасында немецлар, Орел районында элекке хәлне кайтарырга теләп, каршы һөҗүм ясадылар. Ләкин бер участокта да уңышка ирешә алмадылар һәм яңа югалтуларга дучар булдылар. Жиздрадан төньяктарак булган районда гына да дошман 19 нчы марттан 23 нче мартка кадәр булган дүрт көнлек сугышларда 140 танкысын, 72 орудиесен, 202 пулеметын; 137 минометын югалтты һәм 8.000 солдаты һәм офицеры үтерелде.

Немецлар сугыш кырында Сталинград өчен үч ала алмадылар һәм хәзер инде алар бик тырышып кәгазь өстендә үч алырга омтылалар. Гитлерчы ялганчылар тарафыннан юк ителгәннәр разрядына кертелгән совет дивизияләре һәм бригадалары исә үзләренең хәрәкәтләрен дәвам иттерәләр һәм совет җирен немец сволочлардан тәмам азат иткәнчегә кадәр немец илбасарларны тар-мар итәрләр.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Англия эшчеләре икенче фронт ачуны таләп итәлр

ЛОНДОН, 24 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 24 нче мартта хәрби заводларда эшләүче берничә йөз яшь эшчеләр түбәнге палатага килеп, парламент членнары белән очрашканнар һәм парламент членнарының икенче фронтны тизрәк ачуны яклауларын таләп иткәннәр.

Рәсми хәбәрләргә караганда, түбәнге палатага килгән депутация 317 делегаттан торган. Бу делегатлар төрле эшчеләр оешмаларыннан билгеләнгәннәр яки кайбер предприятиеләрдәге эшчеләрнең гомуми җыелышларында сайланганнар. 90 нан артыграк сайлау округындагы 94 оешмадан вәкилләр килгән. Барлык делегатлар 247.000 кешедән вәкил булып килгәннәр. Шушы депутация белән бер үк вакытта түбәнге палатага башка эшчеләр оешмаларыннан да күп кенә делегатлар килгән. Палатага килгән делегатларның гомуми саны 600 кешегә җиткән.

Делегатлар арасында, предприятие эшчеләре белән берлектә, гражданский оборона членнары, шәһәр идарәсе хезмәткәрләре, йорт хозяйкалары һәм башкалар булган.

Югары Савойядагы хәл

ҖЕНЕВА, 27 март. (ТАСС). Швейцария матбугатының хәбәр итүенчә, хәзерге вакытта зур чуалышлар бара торган Клюзга (Югары Савойя) шушы көннәрдә Виши властьлары моторлаштырылган жандармерия отрядлары җибәргәннәр.

Моннан элек Швейцариягә качкан зур бер группа французлар яңадан чик аркылы үтеп, Югары Савойяга кайтканнар. Чиктә патриотларны үзләренең иптәшләре каршы алган әһм, аларны корал һәм азык белән тәэмин иткәннәр. Шуннан соң алар барысы да, бер группа җирле халык белән бергәләп, тауларга киткәннәр.



Америка хәрби диңгез флотының яңа су асты көймәсе. Рәсемдә: иң соңгы типтагы «УСС Биллфиш» су асты көймәсен суга төшерү

ДАНИЯ ПАРЛАМЕНТЫНА САЙЛАУЛАР

СТОКҺОЛЬМ, 25 март. (ТАСС). Даниянең Скавиниус «хөкүмәте», оккупацияләнгән Даниядә әлегә кадәр сакланып килгән кайбер политик партияләрнең басымы астында март башында Дания ригсдагына (парламент) сайлаулар билгеләгән. Германиянең оккупация властьлары парламентка сайлауларга каршы килмәгәннәр, чөнки алар, бер яктан, үзләре тарафыннан булышлык алып килә торган «милли халык партиясе» дип аталган Дания гитлерчыларын һәм башка фашистик группаларны житәрлек санда парламентка үткәрергә мөмкин булыр дип, икенче яктан—оккупацияләнгән илдә парламентка сайлаулар үткәрүне үзләренең яхшы күңеллелекләрен күрсәтү өчен пропагандалауга исәп тотканнар.

Ләкин; 23 нче мартта үткәрелгән сайлаулар, Дания фашистларының бик нык җиңелүе белән тәмам булдылар. Даниядәге башка партияләр белән берлектә парламентка депутат итеп үзләренең кандидатураларын куйган «милли халык партиясе» һәм башка фашистик группалар бары тик 68 мең генә тавыш җыйганнар. Бу аларның гомуми санына карата 2 процент туры килә. миллионга якын сайлаучылар, оккупация властьларына карата һәм Скениус «хөкүмәтенә» карата оппозициядә булган социал-демократик; «сул», консерваторлар һәм башка партияләрнең кандидатураларына тавыш биргәннәр.

Сайлаулар оккупантлар тарафыннан халыкка тупас басым ясау шартларында үткәрелгәннәр, оккупантлар барлык чаралар белән сайлаучыларга Дания фашистик группаларның агентларын тагарга азапланганнар.

ЧИТ ИЛ ЭШЧЕЛӘРЕ ГИТЛЕР КАТОРГАСЫНДА

ҖЕНЕВА, 26 март. (ТАСС). Гитлерчылар матбугаты предприятиеләрдә чит ил эшчеләрен кузәтүне көчәйтү турында Германия властьларының боерыгын басып чыгарды. «Чөнки соңгы вакытларда,—диелә боерыкта,—чит ил эшчеләре тарафыннан кыйммәтле җиһазларны бозу фактлары ешайды». Гитлерчы газеталар Германиядә чит ил эшчеләре тарафыннан һәркөнне диярлек саботаж гактлары булып торуны, шулай итеп бу эшчеләрнең Гитлер каторгасында эшләүгә каршы протест белдерүләре фактын яшерә алмыйлар. Мәсәлән, газеталарның хәбәр итүенә караганда, Штетинда сортировка станциясендә эшләүче француз тимер юлчылары Гамбургка җибәрергә билгеләнгән вагоннарны еш кына башка шәһәрләргә җибәрәләр, шулай итеп транспортның эшен таркаталар. Почтада эшләүче чит ил эшчеләре дә, хәрби оешмаларга җибәрелә торган посылкаларның адресларын юри бутап язалар.

Грециядә Совет-Германия фронтына барырга теләүче „ирекләләр“ табылмаган

ИСТАМБУЛ, 26 март. (ТАСС). Совет—Германия фронтына җибәрү өчен Грециядә «антибольшевистик легион» сештырырга, оккупантларның яңа маташулары барып чыкмаган. Афина университетында «ирекләләр» җыю буенча кампаниянең берничә айлар буена алып барылуына да карамстан; легионга бары тик бер генә студент язылган. Моның өчен бу җинаятьчене студентлар бик нык кыйнаганнар; шуннан соң ул студентлар җыелышында күренмәгән.

ТАССР НАРКОМФИНЫ

Татарстан АССР территориясендә булган барлык учреждениеләрнең, предприятиеләрнең һәм оешмаларның җит әкчеләренә белдерә: СССР Совнаркомының 1935 нче ел, 13 нче майдагы 895 нче номерлы карары һәм СССР Наркомфинының 1943 нче ел, 5 нче февральдәге 72 нче номерлы күрсәтмәсе нигезендә, алар үзләренең 1943 нче ел өчен расланган штатларын, штаттагы һәм штаттан тыш работникларының ставкаларын, хезмәт хакы фондларын, шулай ук административ-хуҗалык расходларының сметаларын шушы елның 1 нче маена кадәр үзенә тиешле

ФИНАНС ОРГАННАРЫНДА ТЕРКӘТЕРГӘ ТИЕШЛӘР

Күрсәтелгән срок үткәннән соң банк органнары, СССР Совнаркомының 1939 нчы ел, 23 нче апрельдәге 547 нче номерлы һәм 1939 нчы ел, 15 нче августтагы 1214 нче номерлы карарлары нигезендә учреждениеләрнең, оешмаларның рәботникларына, шулай ук предприятиеләрнең идарә аппаратлары работникларына хезмәт хакы түләүгә, шулай ук административ-хуҗалык расходларына акчаны бары тик 1943 нче елга штатларны теркәтү турындагы карточкаларны күрсәткәннән соң гына бирәчәкләр.

50-1-1

ТАССР Наркомфины.

10 МЕҢ ТИРАЖЛЫ БЕР БРОШЮРА

«1943 нче елга авыл хуҗалыгын үстерү буенча дәүләт планы турында» ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карарын; Татгосиздат шушы көннәрдә аерым брошюра итеп басып чыгарды. Брошюра татар һәм рус телләрендә, һәркайсысы 5.070 данә тираж белән чыгарылды. Якын көннәрдә бу брошюралар китап магазиннарында һәм киоскаларда сатылачак.

ПИОНЕРЛАР ЯРДӘМЕ

Норлат районы; Малвино авылындагы тулы булмаган урта мәктәп пионерлары һәм укучылар самолетлар эскадрильясе төзү фондына 1.325 сум акча җыеп тапшырдылар. Пионерлар бер үк вакытта металл ватыклары җыю эшен оештырдылар. Алар аз гына вакыт эчендә 400 килограмм металл ватыклары һәм авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау өчен бик күп төрле запас частьлар җыеп тапшырдылар.

Яшелчә орлыклары

Татарстанның Сортсемовощь конторасы предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең ярдәмче хуҗалыклары җиренә утырту өчен 5,2 центнер кәбестә, 2 центнер помидор, 30 центнер чегендер орлыклары әзерләде. Яңадан 225 центнер шикәр чөгендере, берничә центнер башка төрле яшелчә орлыклары алынуы көтелә.

Болардан тыш азат ителгән районнарга 100 центнер чөгендер, 20 центнер кишер орлыклары җибәрелде.

Сортсемовощь конторасы индивидуаль яшелчә бакчалары өчен яшелчә орлыклары әзерләмәгән. Аларга тик рассадалар гына алырга мөмкин булачак. Барлык предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар индивидуаль яшелчә бакчалары өчен кичекмәстән орлык әзерләргә тиешләр

Кызыл Армиягә бүләк

Балтач районындагы «Красный труд» промартеле членнары соңгы көннәрдә Кызыл Армиягә бүләк фондына планнан тыш 40 данә күлмәк, 10 данә сырган чалбар, 2 телогрейка, күп кенә йон, тире һәм башка әйберләр әзерләп тапшырдылар.

Җаваплы редактор **И. ҮЗБЕКОВ.**

ТЕАТРЛАРДА һӘМ КИНОЛАРДА

Татар Дәүләт опера һәм балет театры. 31 нче мартта—**«Ильдар».**

Зур драма театры. Бүген иртән—**«Украина далаларында»**, кич — **«Фронт».** 29 нчы мартта—**«Күренми торган ханым».**

Татар Дәүләт филармониясе. Менжинский исемендәге клубта сәнгать мастерлары катнашы белән зур концерт. 20 сәгать 30 минутта башлана

«Электро». Яңа документаль фильм — **«Сталинград».** «Унион». Көндез һәм кич — **«Моряк кызы».** «Пионер». Көндез — **«Руслан һәм Людмила»** һәм **«Боксерлар»**, кич— **«Минем мәхәббәтем».** «Чаткы». Көндез—**«Экиятләр»** һәм **«Чапаев»**, кич—**«Фронтка концерт».**

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—73—27, Редактор урынбасары АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре 78—93, типография 36—60.

ПФ1091 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 254 01